| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» февраль 2021 с. Тюлячи № 38

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 апрелендәге 173 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2001 елның 15 гыйнварындагы 11/13-09/11 номерлы, 2021 елның 22 гыйнварындагы 11/13-09/236 номерлы хатларын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 апрелендәге 173 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (алга таба текст буенча - регламентлар) (Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 30.12.2013 № 807, 16.07.2014 № 304, 20.07.2015 № 391, 20.05.2016 № 485, 10.11.2016 № 1051, 03.07.2017 № 368, 12.09.2017 № 531, 12.09.2017 № 532, 16.10.2017 № 621, 25.12.2017 № 799, 26.06.2018 № 392, 07.11.2018 № 701, 20.03.2019 № 149, 21.01.2020 № 18, 17.06.2020 № 263, 15.15.2020 № 560, 30.12.2020 № 598, 29.01.2021 № 30, 29.01.2021 № 31 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2 номерлы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы яки булмавы турында белешмә (авария хәлләренә бәйле эшләрне башкару очрагында бирелми).».

2.9 пунктының икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

5) Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар,

процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле бурыч булу (авария хәлләренә бәйле эшләр башкару очрагында бирелми).».

2) биналар һәм корылмалар төзү өчен җир эшләре башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (16 номерлы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы яки булмавы турында белешмә (авария хәлләренә бәйле эшләрне башкару очрагында бирелми).».

2.9 пунктының икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

5) Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле бурыч булу (авария хәлләренә бәйле эшләр башкару очрагында бирелми).».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары - территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге бүлеге башлыгы И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин